РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
Ленина ул., д. 46, с. Тюлячи, 422080

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ
Ленин ур., 46 нчы йорт, Теләче авылы, 422080

тел. (факс): (843) 602-11-89, E-mail: telache@tatar.ru, http://tulachi.tatarstan.ru/

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

**№ 3** **«22» января 2019г.**

Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан финанс контроле алып бару буенча вәкаләтләре кысаларында, чаралар үткәрү исемлеге турында

Татарстан Республикасы Хисап палатасы рәисенең 2019 елның 27 декабрендәге 17/1194 санлы хатын караганнан соң, 2003 елның 6 октябрендәге 131 санлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законга нигезләнеп,

1.Теләче муниципаль районы контроль-хисап палатасына (Фәрхетдинов С.И.) финанс контроле алып бару буенча вәкаләтләре кысаларында 2019 елда тәэмин итәргә:

1.1.Учреждениеләр куллануында (оператив идарә итүдә) булган милекне куллану сферасында:

- учреждениегә оператив идарә итү өчен тапшырылган муниципаль милек (милек) объектлары (аларның өлешләре) белән файдалануга, аерым алганда, арендага бирүгә килешү барлыгы/юклыгына ревизия үткәрү (срогы: ярты елга 1 тапкыр).

- учреждениеләргә оператив идарә итү өчен тапшырылган муниципаль милек (милек) объектларын өченче затларга санкцияләнмәгән (килешенмәгән килеш) тапшыруны ачыклау өчен визуаль тикшерү үткәрү (срогы: ярты елга 1 тапкыр).

- гамәлдәге законнар белән каралган очракларда, Татарстан Республикасы Административ хокук бозулар турындагы кодексының 4.3, 4.4 статьялары буенча административ эш кузгалту турында карар кабул итү.

- арендага, түләүсез файдалануга бирелгән муниципаль милек объектлары исемлегенә, аренда түләвенә, коммуналь хезмәтләргә чыгымнарны тулысынча һәм вакытында кайтаруга ревизия үткәрү.

1. 2.Җир ресурсларын файдалану сферасында:

- территорияләрне максатчан булмаган/законсыз файдалануга, шул исәптән киң таралган файдалы казылмалар чыгару буенча санкцияләнмәгән карьерлар, каты көнкүреш калдыклары чүплеге эшләүгә тикшерүләр үткәрү (шул исәптән, спутник ярдәмендә аэро-фото визуаль күзәтүләр, вәкаләтле органнар белән ярдәмләшеп эшләү) (ай саен).

- китерелгән зыянны бетерү, туфракның уңдырышлы катламын яңадан торгызу (авыл хуҗалыгы җирләрендә) буенча таләпләр кую, гамәлдәге законнар белән каралган очракларда гаепле затларны административ һәм башка җаваплылыкка тарту.

1.3. Бюджет акчаларына башкарылган төзелеш-ремонт эшләренең сыйфаты буенча:

- учреждениеләр администрациясе вәкилләре белән берлектә, гарантия срогы чыкмаган ремонт-төзелеш эшләре башкарылган социаль/җәмәгать инфраструктурасы объектларында, милектән файдалану вакытындагы эш сыйфатына тикшерүләр үткәрү, ачыкланган җитешсезлекләрне вакытында бетерүне тәэмин итү өчен чаралар күрүне таләп итәргә (квартал саен).

- хуҗалык әйләнешендә файдаланылмаучы/җәлеп ителмәүче муниципаль милек объектларына ревизия үткәрү, аларны тотуга нәтиҗәсез чыгымнарны киметүгә/булдырмауга юнәлдерелгән чаралар күрү (ярты елга 1 тапкыр).

2. Әлеге боерыкның үтәлешенә контрольне Теләче муниципаль район Советының аппарат җитәкчесе И.В. Мөбиновка йөкләргә.

И.Ф. Зарипов